ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 05.11.2015 г. Казань № 6-112/тп

Лениногорск ш. «Су каналы» ҖЧҖенең үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) тарифларын билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү Кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 29 июлендәге 644 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны исәпләп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге № 1746-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск ш. «Су каналы» ҖЧҖенең үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) тарифларын әлеге карар кушымтасына нигезләнеп билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2016 нчы елның 1 январеннән алып 2016 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт комитеты
карарына кушымта
05.11.2015 № 6-112/тп

Лениногорск ш. «Су каналы» ҖЧҖенең үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) тарифлары

| № п/п | Күрсәткеч атамасы | Үлчәү берәмлеге | Тоташтыруга тарифлар (НДСтан тыш) |
|---|---|---|---|
| 1. | Тоташтырылучы йөкләнешкә тарифның база ставкасы | тәүлеккә мең сум/куб.м | 1,2319 |
| 2. | Челтәрләр озынлыгына тарифның база ставкасы | мең сум/км | 2 700,34 |
| 3. | Челтәрләр диаметрына бәйле тарифны дифферентлаштыру коэффициенты | | |
| 3.1. | 40 мм һәм аннан кечерәк диаметрлы | - | 0,47 |
| 3.2. | 40 мм – 70 мм (тулаем) диаметрлы | - | 0,47 |
| 3.3. | 70 мм – 100 мм (тулаем) диаметрлы | - | 0,51 |
| 3.4. | 100 мм – 150 мм (тулаем) диаметрлы | - | 0,51 |
| 3.5. | 150 мм – 200 мм (тулаем) диаметрлы | - | 0,51 |
| 3.6. | 200 мм – 250 мм (тулаем) диаметрлы | - | - |
| 3.7. | 250 мм һәм аннан зуррак диаметрлы | - | - |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге